Гыйнвар • 2021 ел • № 1 (37)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы

## Күзгә-күз

*«Театр көлдерәдер, уйнатадыр,*
*Тагы үткән гомерне*
*уйлатадыр»,* –

дип язган бөек Тукаебыз. Без дә театр яратабыз. Чаллы татар дәүләт театры җитәкчеләренең, анда уйнаучы артистларның безнең гимназиягә карата аеруча җылы хисләре һәрдаим сизелеп тора. Күптән түгел театр коллективы безне «Шәһәр.Нокта.Брежнев» премьерасына чакырды. Бернинди чыгымнарсыз, кунак итеп. Әлбәттә, мондый тәкъдимнән кем баш тартсын! Бигрәк тә, күпләрнең әле яңа театр бинасына барганнары юк икән! Искәртергә онытып торабыз икән, 2020 елгы бер яңалыгы – театрга Аяз Гыйләҗев исеме бирелде. Аяз Гыйләҗев күп сандагы драма әсәрләре авторы булса да, беренче чиратта драматург түгел, ул прозаик. Безгә күрсәтеләчәк спектакльнең дә роман жанрындагы әсәрдән драма әсәренә әйләндерелүе безнең өчен кызыклы яңалык иде.

Әлеге тамашага шәһәрнең башка уку йортларыннан укучылар, студентлар килгән иде. Алдан ук кисәтеп куйдылар: яңа форматлы «Шәһәр.Нокта.Брежнев» спектакленең беренче үзенчәлеге – ул ике антракт белән 4,5 сәгать баруында. Мин эчемнән генә, укучыларның сабырлыгы җитәрме икән, дип уйлаган идем, җитте бит! 2 сәгатьлек спектакльне дә озын дип санаган вакытта яшьләрнең игътибарын дүрт сәгать тотарлык булгач, эксперимент уңышлы чыккан дигән сүз.

«Шәһәр.Нокта.Брежнев» – язучы һәм журналист Шамил Идиатуллинның «Город Брежнев» романының сәхнә версиясе. Аңа инсценировканы Олег Кинҗәгулов үзе ясаган. Ул әсәрдән ерак китмичә генә, нигездә әдәби театр тудырган.

Спектакльне карагач, безнең күңелдә уңай һәм каршылыклы фикерләр туды, без театрның әдәби бүлек мөдире Айгөл Әхмәтгалиевага мөрәҗәгать иттек. Безгә тагын бәхет елмайды: Айгөл ханым спектакльне сәхнәгә куйган режиссер һәм спектакльдә катнашкан артистлар белән күзгә-күз очрашу оештырды. (Спектакльдә Татарстанның атказанган артистлары Илфат Әскәров, Миләүшә Имамова, Равил Гыйләҗев. Яшь артистлар – Марсель Мөсәвиров, Алсу Гыйльманова, Винер Фәйзуллин, Фирдүс Сафин, Эдуард Латыйпов, Физалия Габидуллина, Зөлфия Галиуллина катнашкан иде.) Әлеге чарага спектакльне караган өлкән сыйныф укучылары – 2 нче һәм 54 нче гимназия егет-кызлары килгән иде. Артистлар аларның һәм укытучыларның сорауларына җавап бирделәр, хәтта театрның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов тренинг уздырды, очрашу азагында кунакларга театрның истәлекле бүләге тапшырылды.

Безне нәрсә борчыган иде соң? Иң беренчесе, ул да булса спектакльнең башлам өлешендә безгә динамика җитмәү, икенчесе – персонажларны бутау, өченчесе – геройлар кылган гамәлләрне аңлап бетермәү, дүртенчесе – әсәрнең эстетик кыйммәтенә төшенмәү. Безнең сорауларны игътибар белән тыңлаганнан соң, «серле йомгак» сүтелеп китте. Иң беренче эш



*(Ахыры. Башы беренче биттә.)*

итеп, Олег Кинҗәгулов безгә бик үтемле итеп, әлеге әсәрне сәхнәләштерүнең четерекле якларын төшендерде, һәр сүзне, һәр хәрәкәтне, һәр эпизодны тирән уйлап эшләгәннәре турында сөйләде. Без аңлап бетермәгән Виталтольичның ни өчен үлүен аңлатты. «Бу бит үзенә күрә символ. Кеше үз амбицияләре, теләкләре белән бу шәһәргә килгән. КамАЗ йөкләмәләре белән йөри. Ә аңа: «Син дурак, нигә болай эшләдең?!» – диләр. Артурның этисе Вазыйх белән мөнәсәбәтләре бозыла. Ул үзенең карашлары белән бу җәмгыятькә кирәкми башлый. Хәтта аннан Артур да баш тарта. Димәк, ул физик үлеменә кадәр үк үлә.» Аннан килеп, без тамашачы буларак, игътибардан читтә калдырган музыкаль бизәлешкә тукталды. Үз чиратыбызда, без тамашачы буларак, кабул итеп үк бетерә алмаган укытучы кыз Марина образының бирелеше белән килешеп бетмәвебезне белдердек, ләкин бу автор Шамил Идиатуллинның идеясе икәнен дә онытмадык.

««Шәһәр.Нокта. Брежнев» – Чаллы театрының яңартылу символы. Алдагы бер ел эчендә Чаллы театры зур үзгәрешләр кичерде: театр белән идарә итү системасы үзгәреп, коллективка сәнгать җитәкчесе билгеләнде. Олег Кинҗәгулов тумышы белән Уфадан, Фәрит Бикчәнтәев укучысы», – дип интернет челтәрендә язылып чыккан мәгълүматның дөреслегенә төшендек. Олег Кинҗәгулов безгә – мәктәп укучыларын ияртеп килгән укытучыларга – зур хөрмәт белән карады, вакыт белән хисаплашмыйча, артистлар тормышының эчке тәртибе хакында сөйләп кенә калмады, безнең белән тренинг уздырды.

Минем күңелдә бер сорау калды: спектакльгә килгәнче, башта романны укырга, аннары карарга килергәме, әллә киресенчәме? Ничек кенә булмасын, минем әлеге спектакльне тагын карыйсым килә. Спектакльне сез дә карагыз, чөнки үз шәһәреңнең тарихына, сәнгатенә битараф булырга безгә һич тә ярамый. Театр артистларына, җитәкчеләренә яңа иҗади уңышлар теләп, тамашачы рәхмәтен җиткерәбез.

**Энҗе НУРИСЛАМОВА**



*Фоат абыйның күңелендә һәрвакыт матурлыкка тартылу, кешеләргә карата шәфкать хисе яши. Мондый алтын куллы кешеләр безнең арада сирәк, шуңа күрә алар өчен җылы сүзебезне әйтергә кайчак вакыт та җитми. Фоат абый турында язма «Шәһри Чаллы» газетасында басылып чыккач, бик сөендем. Әлеге язманы сезгә дә тәкъдим итәм, чөнки без Антуан Сент-Экзюпериның «Нәни принц» әсәрендәге кебек бер-беребез өчен җаваплы булырга һәм уңышларга игътибарлы булырга тиешбез.*

**Энҗе НУРИСЛАМОВА**

# Алтын куллы Фоат абый

Шәһәрдәшебез Фоат Закиров туган ягы Саба районының гына түгел, Чаллының да горурлыгы. Аның «алтын куллары» искиткеч матур әйберләр ясый. Фоат абый агачтан мәчет, борынгы йорт җиһазлары, транспорт һәм башка предметлар ясап бүләк итә. «Борынгы йорт җиһазлары, көнкүреш кирәк-яракларын ясарга яратам, чөнки алар хәзер бетеп бара. Минем халкыбыз элек кулланган әйберләрне киләчәк буыннарга күрсәтәсем, тарихыбызга үз өлешемне кертеп калдырасым килә», – ди язмам герое.

Ул Саба районы Сабабаш авылы егете. Язмышын 1977 елда Чулман буендагы автокала белән бәйләгән. Аңа кадәр Саба урман хуҗалыгында урманчы, техник-урманчы булып эшләгән. Аңа бу сәләт этисеннән күчкәндер, мөгаен. «Әтием бик уңган балта остасы иде», – ди Фоат абый.

Язмыш Чаллыга китергәч, балалар бакчасында балаларга «подделка»лар кирәк була башлагач, ул яраткан һөнәре белән ныклап шөгыльләнә башлый. Бүгенге көндә аның төрледән төрле 500дән артык әйбере бар. Аларның күбесе Сабада һәм Сабабаш мәктәп музеенда саклана. Моның өчен якташлары аңа рәхмәтле.

Ул ясаган әйберләр шәһәрнең үзәк китапханәсендә, экология музеенда, «Нур Ихлас» мәчетендә саклана.

Фоат абый тарихи темаларга иҗат итәргә ярата. «Татар авылы ишек алды» дигән темага йорт кирәк яраклары: эш кораллары, арба, мотоцикл, чана ише әйберләрне аеруча яратып ясый. Ул ясаган «Уфалла арбасы» аеруча популяр булган. Фоат абый аны шул исемдәге җыр авторларына да, Татарстанның халык артисты Габделфәт Сафинга да бүләк иткән.

Ул Тукай иҗаты буенча да әйберләр ясый. Экология музеенда аларны күреп, үзем дә сокланып кайткан идем.

Фоат Закиров әйберләрне заказга да ясый, тик күбрәк бүләк итәргә ярата. «Кечкенә әйберләрне өемдә, ә зурларын бакчамда ясыйм», – ди ул.

«Фоат абый бик кешелекле кеше. Балалар аңардан эш кораллары белән эшләргә, пөхтәлеккә, хезмәтне яратырга өйрәнәләр. Гимназиядә укыганда улым аның дәресләренә бик теләп йөрде. Хәзер Фоат абыйсына гел рәхмәт укып йөри. Өендә ватылган әйберләрне үзе ясап куя, балаларына бакчага кирәкле «Подделкалар»ны да малайлары белән бергә ясый. Шулай итеп улларын кечкенәдән үк хезмәтне яратырга өйрәтә», – ди шәһәрдәшебез Гөлия Вәлиева.

Фоат абый кешелекле, ярдәмчел. Ул кешеләргә матурлык бүләк итәргә ярата. Матур әйберләрне үз куллары белән тудыра. Мәчетләр арбалар, йорт җиһазлары музейларда, Аллаһ йортларында, кешеләрнең фатирларында, бакчаларында ямь биреп тора. Ул вакытын бушка исраф итми. 2021 елда Аллаһы боерса, аңа 70 яшь тула. «Юбилеема агачтан Кол Шәриф мәчетен ясарга җыенам», – ди ул. Изге ниятләрен тормышка ашырырга Аллаһ ярдәм итсен үзенә.

**Зөлфия ФОАТОВА**

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
2021
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Тел ул – кешеләрне хайваннардан аерып тора торган сыйфат, кешеләрнең аралашуы өчен иң әһәмиятле чара. Телсез дөньяны күз алдына китерергә бик кыен. Ләкин бөтен дөнья бер телдә генә сөйләшми, һәрбер милләтнең үзенең теле бар, ә алар җиде меңнән артык. Баланың беренче әйткән сүзе дә, туган телендә яңгырый.

Минем туган телем – татар теле. Ләкин мин яшәгән шәһәрдә ул телдә сөйләүче кеше бик аз. Ә милләтнең теле «үлсә», милләт тә үлә. Шуның өчен тел – милләтнең иң ышанычлы сакчысы.

**Аяз ГАТАУЛЛИН,**
*7А сыйныфы*

Тел – ул кешеләрне дөньядагы башка төрле җан ияләреннән аерып тора торган могҗизалы күренеш. Ул – җәмгыятьне оештыра, кешеләрне үзара аралаштыра.

Телебезне өйрәнергә, аны даими рәвештә бастырга, үстерергә тиешбез. Ләкин хәзер кешеләр туган телебездә бик аз сөйләшәләр, шуңа күрә телебез юкка чыгарга мөмкин. Телебез бетсә, халкыбыз да бетәр! Бала үзенең телендә сөйләшергә тиеш. Кеше хисләрен туган телендә генә әйбәт итеп белдерә ала. Тел – кешеләрнең аралашуы өчен иң әһәмиятле чара. Ул – тормыш чыганагы.

**Зилә НУРИЕВА,**
*7А сыйныфы*

## Горурлыгым

Татар теле – туган телем.
Туган җирем – Татарстан.
Туган телдә белем алам
Шуның белән горурланам!

**Лиана ФАТТАХОВА**

Минем туган телем – татар теле. Бала чагымда мин татар телен бик аз белә идем. Өйдә мин русча сөйләштем, чөнки әтием рус иде. Балалар бакчасында да безнең белән русча сөйләштеләр. Миңа биш яшь тулгач, әни минем белән татарча сөйләшә башлады. Татарча сөйләшергә мин бик яратмый идем: ник соң янымдагы бөтен кеше русча сөйләшә, ә мин юк?! Ләкин әни бер әйбер уйлап тапты: мин татарча әйбәт сөйләшкәндә, миңа теләгән уенчыкны алып бирәләр иде. Тора-бара шушы телдә сөйләшергә өйрәндем. Хәзер мин татар телендә әйбәт сөйләшәм. Әбиләр янында оят түгел. Татар җырларының мәгънәсен аңлыйм. Ничек без телебезне саклыйбыз? Бик җиңел. Гаиләдә гел татарча сөйләшәбез, татарча китаплар, журналлар укыйбыз, концертларга йөрибез.

**Айсылу ЗУЕВА,**
*7А сыйныфы*



# Ватан сакчысы

## Хафиз бабама ачык хат



Исәнме, Хафиз бабай! Сиңа Чаллы шәһәре 2 гимназиянең 9 нчы сыйныфында укучы оныгың Айнур хат яза. Кызганычка каршы, мин синең белән очрашып сөйләшә алмыйм, шуңа күрә хат язарга булдым. Әнием һәм әбием сөйләгәннәрдән синең турыда мин түбәндәгеләрне белдем: бабам, Гыйниятов Хафиз, 1911 елда Татарстанның Әлки районы Татар Борнае авылында туган. Сугыш башланганның икенче көнендә ук сугышка киткән. Әбием, син киткәч, өч айдан соң гына туган. Әбием сине хәтерләми дә, ул әнисенең сөйләве буенча гына белә. Хафиз бабай Сталинград сугышына җибәрелгән. Беренче бәрелешләр вакытында ук һәлак булган.

Кадерле бабам, син минем генә түгел, безнең гаиләнең саклаучысы, Ватаныбыз герое. Мин сиңа бәхетле балачагым өчен рәхмәт әйтәм. Чөнки син киләчәк буыннар өчен азат, бәхетле тормыш өчен көрәшкәнсең. Моннан тыш синең истәлегеңә атап, мин ишегалдында бер агач утырттым. Ул агачым үсә, ныгый бара. Сиңа карата булган хөрмәтем, синең турында булган истәлекләрем, шушы агач кебек, бары тик ныгый гына!

*Оныгың Айнур Гыйләҗев.*

## Кыш бабай

Кыш бабай, Кыш бабай,
Аның сакалы иң бай.
Капчык белән ул килде
Һәм аннан бүләк бирде.
Кыш бабайның дуслары бар,
Пошилар һәм боланнар.
Ул бит безнеңчә сөйләшә,
Димәк, Кыш бабай- татар!

**Фәрхәт ГАТИН,**
*4А сыйныфы*

## Табышмак

Йомшак була, ак була,
Кояшта көмеш була.
Салкын була, вак була
Ул зуррак та була.
Ул ни икән? Әйт миңа!

**Айназ ГАРАЕВА,**
*4В сыйныфы*

## «К» хәрефенә кызык хикәя

Карлы, кояшлы кыш. Көтелгән кышкы каникуллар. Кар көртләре кабарып күренә. Кинәт күңелле каркылдаган каргаларның кычкыруы колакка керә. Канатларын кага-кага, кечкенә каргалар көрттә коеналар, күңелле каркылдашалар, кунган карларын кагалар.

Кибеттән кайтучы күршеләр Кәрим, Камил кулында кәгазьле конфетлар. Камил, каргалар капсынга, конфетын кошларга кизәнде. Конфет карга кадалды. Каргалар куаныштылар. Каргалар конфетка кызыгып карадылар, кабып куйдылар. Кәефләре күтәрелеп, кабаттан кар көртендә каркылдаштылар.

Күршеләр калган конфетларын, күчтәнәчкә Кәшиф картка керттеләр. Картның кар көртләрен кызукызу көрәделәр. Көлешә-көлешә, кирегә кузгалдылар. Кайтканда, кызып-кызып көрәштеләр. Кызык, купшы кар көрәшчеләрне көйләп кенә күтәрә. Көрәш киләчәктә күплəгән кубоклар, керемнәр китерер кебек.

Камил, Кәрим, кичен күтәренке кәефтә кайтып киттеләр.

**Мәликә ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,**
*6А сыйныфы*

## Авылым чишмәсе

Безнең авылда Чәтрән чишмәсе бар. Анда матур гына кечкенә өй ясалган, ә башында тимер әтәч утыра. Аның эченнән челтерәп салкын су агып чыга. Ул бик матур, ә суы искиткеч тәмле һәм әбием әйтә «әле шифалы да!»

Чишмәбезнең исеме килеп чыгу тарихы болайрак. Элекке вакытта авыл урынында бик күп чишмәләр булган. Алар челтер-челтер акканнар. Әби-бабайлар шуңа күрә авылыбызга Чәлтерән исеме кушканнар. Хәзерге вакытта бу исем кыскартып халык телендә Чәтрән булып калган. Шул элекке чишмәләр хөрмәтенә авылыбызның чишмәсендә дә Чәтрән дигән исем сакланган.

Җәй көннәрендә бабаем белән чишмәгә еш барабыз, су алабыз, ә кайткач чишмә суыннан чәй кайнатабыз. Бабаемның умарталыгында җыелган бал белән тәмләп чәй эчәбез! Ммм, кайчан җәйге каникул җитәр инде! Тагын чишмәгә барыр идек...

Безнең тирәләрдә булсагыз, сез дә, дуслар, Чәтрән чишмәсе суын авыз итмичә китмәгез!

**Ясминә ФӘТХЕТДИНОВА,**
*3В сыйныфы*



## Ташасты чишмәсе

Мин үземнең кече Ватаным дип Минзәлә районындагы Җәмәк авылын саныйм, чөнки анда яраткан әтием туган һәм Гафиятовлар нәселе 300 ел буена монда яшәгәннәр. Җәмәк авылы, борма-борма булып аккан Минзәлә елгасы буенда урнашкан.

Безнең якта чишмәләр бик күп. Авылдан елга буйлап бераз барсаң, элекке заманнан калган таш карьеры очрый. Шул заманнарда Минзәлә шәһәре янында, Әби патша килеүнә дип, тимер дамба төзегәннәр. Шуның нигезенә моннан казып алынган күптонналы ташларны куйганнар. Халык телендә бу җирне Ташасты дип йөртәләр. Монда элек мамонт сөякләре һәм казык тешләре таба торган булганнар. Алар мәктәп музеенда да бик күп. Менә шушы серле урында бик матур чишмә җир астыннан чыгып, челтерәп агып ята. Ташасты чишмәсенең суы тешне сындырырлык салкын, чип-чиста һәм файдалы.

Безнең авылда тагын бер серле һәм кызык чишмә бар. Су җир астыннан фонтан булып 3-4 метрга өскә атып тора. Минем мондый чишмәне бервакытта да күргән юк иде әле. Әтием аңлаткач кына, аның чын чишмә түгеллеген, ә ясалма икәнлеген белдем. «15 ел элек нефть эзләүчеләр җирне бораулап, су катламына чыкканнар. Нефть табылмагач, торбаларны бөкеләп, басым кимесен өчен тишек калдырып киткәннәр. Менә шул вакыттан бирле су фонтан булып атып тора», – дип сөйли әтием. Кызганычка каршы, аның суыннан күкерт исе килә.

Мин авылга каникулларга кайткач, әтием белән чишмәгә бармыйча калмыйбыз. «Чишмәне сакларга кирәк! Аның шифалы суын ничә буын әби-бабайларыбыз эчеп, тәннәренә һәм җаннарына сихәт алганнар бит», – ди әтием.

**Луиза ГАФИЯТОВА,**
*3В сыйныфы*

Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА • **Редактор-координатор:** Э. А. НУРИСЛАМОВА